ГЛАВА
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.12.2024 Баулы шәһәре № 173

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы "Покров-Урыстамак авылы җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проекты буенча иҗтимагый фикер алышуларны билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Баулы муниципаль район Советының 2018 елның 3 июлендәге 160 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар, (иҗтимагый фикер алышулар) үткәрү тәртибе турында Нигезләмәсе, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Уставының 17 статьясы нигезендә

КАРАР ИТӘМ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының " Покров-Урыстамак авылы җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проекты буенча иҗтимагый фикер алышуларны уздыруны билгеләргә (алга таба - Проект).
2. Проект буенча иҗтимагый фикер алышулар инициаторы – Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башлыгы.
3. Иҗтимагый фикер алышулар уздыру вакытын 2024 елның 5 декабреннән 18 декабренә кадәр билгеләргә.
4. Иҗтимагый фикер алышуларда каралачак Проект экспозициясен 2024 елның 5 декабрендә ачарга.

4.1. Экспозицияне уздыру урыны:

- Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Покров-Урыстамак авылы җирлеге Башкарма комитеты бинасында Татарстан Республикасы, Баулы районы, Покров-Урыстамак авылы, Совет урамы, 65А йорт адресы буенча;

- Баулы муниципаль районы сайтында www.bavly.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә.

4.2. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Покров-Урыстамак авылы җирлеге Башкарма комитеты бинасындагы экспозицияне барып карау режимы түбәндәге адрес буенча: Баулы муниципаль районы, Покров-Урыстамак, Совет урамы, 65А йорт, эш көннәрендә Мәскәү вакыты буенча 8.30 - 11.30 һәм 13.30 - 16.00 сәгатькә кадәр.

5. Җәмәгать фикер алышуларында катнашучылар 2024 елның 5 декабреннән 18 декабрьгә кадәр, Мәскәү вакыты белән эш көннәрендә 8.30 дан 11.30 га кадәр, 13.30 дан 16.00 сәгатькә кадәр җәмәгать тыңлауларында каралырга тиешле проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм кисәтүләр кертергә хокуклы:

- иҗтимагый фикер алышулар оештыручыга, язма рәвештә, түбәндәге адрес буенча: Баулы шәһәре, Куйбышев урамы, 20 йорт,  101 каб;

6. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы итеп, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы  Башкарма комитетын (алга таба - иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы) билгеләргә.

7. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручыга:

7.1. Проектны карау буенча иҗтимагый фикер алышуларны уздыруны тәэмин итәргә;

7.2. Проект буенча иҗтимагый фикер алышуларны уздыру башлану турында хәбәр итүне, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль берәмлеге, Покров-Урыстамак авылы җирлеге Башкарма комитеты бинасында мәгълүмат стендында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга;

7.3. Экспозицияләрне Татарстан Республикасы Баулы муниципаль берәмлеге, Покров-Урыстамак авылы җирлеге Башкарма комитеты бинасында, 2024 елның 5 декабренннән 18 декабренә кадәр, эш көннәрендә, Мәскәү вакыты белән 8.30-11.30, 13.30-16.00 сәгатьләрдә, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Баулы муниципаль районы сайтында www.bavly.tatarstan.ru оештырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы

Башлыгы И.И. Гозәеров